КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 236

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карары белән расланган Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 июнь, 418 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 796 нчы; 2020 ел, 26 июнь, 534 нче, 2021 ел, 31 май, 420 нче; 2022 ел, 19 февраль, 139 нчы; 2022 ел, 7 июль, 650 нче, 2022 ел, 29 ноябрь, 1267 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«иҗтимагый оешмалар чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә

активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.2 пунктта:

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы үтәлеше турында белешмә формасын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендщге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын салым түләүче (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәү турында салым органының белешмәсе»;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«иҗтимагый оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган белешмә кәгазен;»;

3.2 пунктта «айның 10 числосыннан да соңга калмыйча» сүзләрен «айның 15 числосыннан да соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин